**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3754**
**10.05.2023**

Башкарма комитетның 2020 елның 20 маендагы 2336 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелеген гамәлгә ашырганда, контроль чараларны үткәргәндә үтәлеше бәяләнә торган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын гамәлдән чыгару турында» 2020 елның 8 октябрендәге 1631 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 20 маендагы 2336 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибенә, 9 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1) Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.3/2.4.3590-20 СанПИН санитар-эпидемиологик кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2020 елның 27 октябрендәге 32 номерлы карары нигезендә кабул ителә торган тәрбияләнүчеләрнең туклану нормалары.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында

(http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов